СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

15.12.2020 ел Баулы шәһәре № 24

Авыл хуҗалыгы җирләрен
хосусыйлаштыру вакытына
билгеләнгән гражданнар
милкенә җир кишәрлекләрен
бушлай тапшыруның уртача
район нормасын раслау турында

Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 статьясы 1нче пункты, 40 статьясы 2нче пункты нигезендә, крестьян (фермер) хуҗалыгына ул үз эшчәнлеген дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә тормышка ашырсын өчке милек итеп бирелә торган җир участокларының чик минималь күләмен билгеләү максатларында Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына гражданнарның милкенә җир кишәрлекләрен бушлай тапшыруның уртача район нормасын 5,05 гектар күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советы рәисе урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин